**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 8 октябрь № 750

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 23 гыйнвар, 34 нче, 2015 ел, 13 март, 151 нче, 2015 ел, 10 июль, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән, әмма дәүләт йөкләмәсен (заказын) үтәүдә катнашмый торган социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән тәэмин итүче ай саен, агымдагы айның 20 сеннән һәм хисап аеннан соң килүче айның 20 сеннән дә, шулай ук агымдагы елның 15 декабреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – территориаль социаль яклау органы) компенсация түләү өчен бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\750.docx